Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең
Октябрина поселогы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

15 ноябрь 2019 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегенең Октябрина поселогы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм аларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару.

2) Урамнарны яктырту (ремонт, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)».

Халык җыены рәисе: О.В.Охотникова

Елаур авыл җирлеге башлыгы: О.В.Охотникова